РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» ноябрь 2024 ел г. Альметьевск № 3686

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Башкарма комитетының
«Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында»
2021 елның 27 маендагы 748 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 22 июлендәге 194-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 27 маендагы 748 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 10 апрелендәге 869 номерлы, 2023 елның 13 ноябрендәге 5053 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Каракга 1 нче кушымтада:

- 2.8.3 бүлекчәсенең 2.8.3.2 пунктының 8), 9), 10) пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә башка зат белән төзелгән йә аны комплекслы үстерү турында Карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, җир кишәрлеген бирү турында гариза белән мондый җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, андагы урыннар, тәмамланмаган төзелеш объекты милекчесе яисә мондый җир кишәрлегенең Хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;

9) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән йә, күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән яисә җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир

кишәрлегеннән төзелгән территория чикләрендә урнашкан, мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеген бирү турында гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;

10) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән, әлеге затның күрсәтелгән объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тотып, җир кишәрлеген арендага бирү турында гариза белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;»;

2.10 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге» 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.А. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А. М. Каюмов